**ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ РЫБНО-СЛОБОДСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**

422650, пгт. Рыбная Слобода,
ул. Ленина, дом 48

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ БАЛЫК БИСТӘСЕ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫНЫҢ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ**

422650, Балык Бистәсе,
Ленин урамы, 48 нче йорт

Тел.: (84361) 22113, факс: (84361) 23012, e-mail: balyk-bistage@tatar.ru, сайт: ribnaya-sloboda.tatarstan.ru

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

26.03.2018 пгт. Рыбная Слобода № 61пи

Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Башкарма комитетының «Татарстан Республикасы бюджет өлкәсе хезмәткәрләренә хезмәт өчен түләү буенча бердәм тариф челтәре кагылмаган Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районының аерым оешмалары хезмәткәрләренең хезмәт өчен түләү шартлары турында» 29.09.2017 ел, №216пи карарына үзгәреш кертү хакында

Муниципаль норматив хокукый актны законнарга туры китерү максатларында, «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль Законның 47 статьясындагы 2 өлеше, Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Уставының 74 статьясындагы 3 өлеше нигезендә КАРАР БИРӘМ:

1. Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Башкарма комитетының «Татарстан Республикасы бюджет өлкәсе хезмәткәрләренә хезмәт өчен түләү буенча бердәм тариф челтәре кагылмаган Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районының аерым оешмалары хезмәткәрләренең хезмәт өчен түләү шартлары турында» 29.09.2017 ел, №216пи карарына түбәндәге үзгәрешләр кертергә:

13 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«13.Бу карар рәсми бастырып чыгарылганнан соң (халыкка игълан ителгәннән соң) үз көченә керә һәм 2017 елның 1 октябреннән барлыкка килгән хокук мөнәсәбәтләренә кагыла дип билгеләргә.».

2. Әлеге карарны http://pravo.tatarstan.ru. веб-адресы буенча Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге “Татарстан Республикасының хокукый мәгълүмат рәсми порталы”нда һәм Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районының http://ribnaya-sloboda.tatarstan.ru. веб-адресы буенча Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайтында игълан итәргә..

3. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Татарстан Республикасы

Балык Бистәсе муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесенең икътисадый мәсьәләләр буенча урынбасары И. Р. Хисмәтовка йөкләргә.

Җитәкче И. Р. Таҗетдинов